2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авылы җирлеге Яңа Нәдер авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

21 ноябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, хатыны һәм балалары) һәм 1 төркем инвалидлардан тыш

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә: торак пункт территориясен төзекләндерү (авария хәлендәге агачларны кисү, куакларны кисү), традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (авария хәлендәге агачларны кисү, куакларны кисү, җирне чүп үләннәреннән эшкәртү)?".

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Яңа Нәдер авылы, Совет урамы, 81 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Нәдер авыл җирлеге башлыгы С.М. Миннебаев